РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
СОВЕТ МИЧАНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422055, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с.Старый Мичан, ул. Школьная, 12
тел. (84362) 42-3-31

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
МИЧЭН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
422055, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Иске Мичэн авылы, Мэктэп урамы,
12 йорт
тел. (84362) 42-3-31

e-mail: mich.Sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ

КАРАР

23.10.2024

№ 23

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Мичән авыл
җирлеге территориясендә физик затлар
мөлкәтенә салым турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге нигезендә Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

**1.** Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Мичән авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә түләү мәҗбүри булган салым билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

**2.** Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

**1)** 0,1 процент:

гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан, әлеге карарның 2 пунктының 4 бүлегендә күрсәтелгән урыннар;

һәркайсының мәйданы 50 квадрат метрдан артмаган һәм шәхси ярдәмче хуҗалык, хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык яисә индивидуаль торак төзелеше алып бару өчен җир кишәрлекләрендә урнашкан хуҗалык корылмалары яисә корылмалары;

мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина урыннары. Ставка салым түләүче сайлаган бер гаражга яисә машина урынына карата билгеләнә.

**2)** 0,2 процент:

– торак йортлар, торак йортларның өлешләре;

– төгәлләнмәгән төзелеш объектлары, объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән Бердәм күчемсез комплекслар;

**3)** Фатирларга, фатирларның өлешләренә, бүлмәләргә карата 0,3 процент;

**4)** 2025-2027 еллар чорына 1,2 процент, 2028 елда һәм аннан соңгы елларда – гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән урыннарга һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацы нигезендә билгеләнә торган салым салу объектларына карата 2 процент;

**5)** Һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып киткән салым салу объектларына карата 2 процент;

**6)** Башка салым салу объектларына карата 0,5 процент.

**3.** Түбәндәге ташламаларны билгеләргә:

3.1 Ике фатирдан торган күпфатирлы бер катлы торак йорттагы фатирга милек хокукына ия физик затларга исәпләнгән салым суммасын әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрының кадастр бәясендә салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага киметү рәвешендә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташлама суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукындагы өлешенә пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Бу чакта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташлама суммасы исәпләнгән салым суммасыннан аны исәпкә алмыйча гына арта алмый.

3.218 яшькә кадәрге өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнар- физик затлар балалары мөлкәтенә салым түләүдән азат итәргә.

Салым ташламасы салым салу объектларының чикләнмәгән санына карата бирелә.Салым ташламасы салым салуның теләсә нинди төр объектларына карата бирелә.Салым ташламаларына хокуклы физик затлар салым органына үз теләкләре буенча салым ташламасы бирү турында гариза бирәләр, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документлар бирергә хокуклы.".

4. Үз көчен югалткан дип танырга:

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында" 14.11.2014 елның 28 номерлы карарын;

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 07.08.2015 елның 25 номерлы карарын;

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 08.10.2015 елның 7 номерлы карарын;

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 06.08.2018 елның 16 номерлы карарын;

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 21.11.2018 елның 32 номерлы карарын;

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 25.03.2019 елның 11номерлы карарын;

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 26.11.2019 елның 31 номерлы карарын;

Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлегенең "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге территориясендә физик затлар мөлкәтенә салым турында 14.11.2014 елның 28 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 19.02.2024 елның 5 номерлы карарын;

5. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан, әмма халыкка игълан ителгән көннән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

6.Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматлар турындагы рәсми порталында мәгълүмати-телекоммуникацион “Интернет” челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы, авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Мичән авыл җирлеге рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/rus/mishan_ адресы буенча урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Мичән авыл җирлеге башлыгы: А.Ә.Гәрәев